КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 август г.Казань № 746

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатла-рында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибен раслау турында» 2018 ел, 3 июль, 539 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатла-рында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары

буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибен раслау турында» 2018 ел, 3 июль, 539 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатла-рында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибендә:

2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы вәкилләре;»;

9 пунктта «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин